Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт авыл Советы

КАРАРЫ

12 май 2020 ел                                                                                    № 132

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Уставның XIV бүлегенә кертелгән үзгәрешләр белән бәйле рәвештә, 2020 елның 16 мартындагы ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып,

Әлмәт авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Уставында кушымта нигезендә үзгәрешләр кабул итәргә.
2. Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Уставындагы үзгәрешләрне Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.
3. Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Уставындагы үзгәрешләр рәсми теркәлгәннән соң Әлмәт авылы, Яшьләр бистәсе, Школьная урамы, 3 нче йорт; Дербедень авылы, Совет урамы, 32 нче йорт; Бота урманчылыгы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Әлмәт авыл җирлеге башлыгы                                        А.А. Веретенцев

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы
Әлмәт авыл Советының
2020 елның 12 маендагы
132 номерлы карарына
1нче кушымта

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге
Уставына үзгәрешләр кертү турында

1) 5 статьяның 1 өлешен түбәндәге эчтәлекле 20 пункт белән тулыландырырга:

«20) үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә карар кабул итү, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү яисә билгеләнгән таләпләргә туры китерү турындагы карар).»;

2) 25 статьяда:

а) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) коммерция яисә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органында түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) коммерциягә карамаган оешма белән идарәитүдә (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы, Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәр итеп, башка иҗтимагый оешманың съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашудан тыш) катнашу;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә яклау;

г) идарәһәм ревизия комиссиясе органнарында гамәлгә куючысы (катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманың муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә яклау, муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектәге акцияләргә идарә итү тәртибен (Устав капиталындагы өлешләр) билгели торган

муниципаль хокукый актлар нигезендә;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар»;

3) укытучы, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә.Шул ук вакытта укытучылар, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында каралмаган булса;

4) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, коммерциячел хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә аларның структур бүлекчәләре составына керергә.»;

б) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Җирлек депутаты «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш. Җирле үзидарәнең сайланулы органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарыаларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аерым категория затларга счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалануны тыю» турында 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тыюларны һәм бурычларны үтәмәгән очракта вакытыннан алда туктатыла, әгәр дә«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса.

в) түбәндәге эчтәлекле 8-11 өлешләре белән тулыландырырга:

«8.Депутатның керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү, коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты тарафыннан Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) карары буенча Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

9. Әлеге статьяның 7.2 өлеше нигезендә уздырылган тикшерү нәтиҗәсендә «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү фактлары ачыкланганда, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарыаларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категория затларга счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалануны тыю» турында 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә

күрсәтелгән затларга карата тиешле карарны кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка башка җаваплылык чарасы куллану турындагы гариза белән мөрәҗәгать итә.

10. Җирле үзидарәнең сайланулы органы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына, үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына,шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, әгәр бу белешмәләрне бозу җитди булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органы депутатын, җирле үзидарәнең сайланулы органы вазыйфасыннан, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органындааның вәкаләтләре чоры тәмамланганчывазыйфасын биләү хокукыннан мәхрүм итү;

3) даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкару хокукыннан мәхрүм итеп азат итү;

4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы вазыйфаларны биләүне тыю;

5) вәкаләтләр чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкаруны тыю.

11. Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата әлеге статьяның 8-10 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.

3) 38 статьяның 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Җирлек башлыгы «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш.

Депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының,җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләре «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәгән очракта вакытыннан алда туктатыла, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарыаларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалануны тыю» турында 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса.»;

4) 44 статьяда:

а) 1 өлешнең 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац өстәргә:

«- үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә карар, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү яисә билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карар кабул итү.»;

б) 1 өлешнең 4 пунктын төшереп калдырырга;

в) 1 өлешнең 6 пунктына түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

«-халыкны элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыруны тәэмин итә;»

5) 74.3 статьяда:

а) «Субсидия» сүзеннән соң «дотацияләр» сүзен өстәргә;

б) 2 өлештә «бирелгән» сүзеннән соң «дотацияләр һәм» сүзләрен өстәргә;

6) 74.4 статьясында.

а) «Субсидия» сүзеннән соң «субвенцияләр» сүзләрен өстәргә;

б) 4 өлештә «төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга» сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

«5. Җирлек бюджетына башка муниципаль берәмлекләр бюджетларыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә субсидияләр бирелергә мөмкин.»

7) 79 статьяда:

а) 1 өлешнең беренче абзацында «Россия Федерациясе бюджет законнарында һәм башка норматив» сүзләрен «нигезләмәләре» сүзенә алмаштырырга, «физик затларга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан гавами норматив йөкләмәләр һәм башка түләүләр буенча йөкләмәләр, шулай ук бюджеттан акчалар бирү турында дәүләт (муниципаль) контрактлары, шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәү хокукый актлар» сүзләрен өстәргә.;

б) 2, 3 өлештә, «бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә» сүзләрен төшереп калдырырга.

Әлмәт авыл җирлеге башлыгы А.А. Веретенцев